Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2021 елның 14 декабрь № 36

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге
аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча
вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының түбәндәге вәкаләтләрен Түбән Үрәс авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзи.

Җирлек Башлыгы Р.Х.Шамеев